МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.01.2018 Казан шәһәре № под-145/18

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Положениегә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт органының Кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 1 мартындагы 96 номерлы Указы белән расланган Федераль дәүләт органының Кадрлар резервы турындагы Положение нигезендә б о е р а м:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 22 ноябрендәге № под-2245/16 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры» сүзләрен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (аның вазыйфаларын башкаручы затлар) сүзләренә алмаштырырга)»;

3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Әлеге Положениенең 4 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, дәүләт хезмәте өлкәсендә

дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында, аларны кабул итү турында игъланнар урнаштырылган көннән алып 21 календарь көн эчендә, почта аша яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасын кулланып, дәүләт органына граждан тарафыннан (граждан хезмәткәрләре ), шәхсән, почта аша яисә электрон рәвештә җибәрелә.

Электрон рәвештә бирелгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автомат рәвештә тикшерелә »;

3 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункт белән тулыландырырга:

«3.4. Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә, тикшерү барышында гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулаучы фактлар ачылса, министр аңа, ни өчен конкурста катнашаша алмау сәбәпләре турында, язма формада хәбәр итә. Әгәр граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырса, аңа конкурста катнаша алмау сәбәпләре турында хәбәр көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланып җибәрелә.»;

4.4.5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча), конкурсның икенче этабын үткәрү вакыты һәм урыны турында Карар кабул итә. Дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматка рөхсәт алган очракта, конкурсның икенче этабын үткәрү вакытын министр билгели.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Кадрлар сәясәте бүлеге конкурсның икенче этабы башланганчы, 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеге

урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язма рәвештә җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, әлеге мәгълүмат системасын кулланып, электрон рәвештә тәкъдим иткән кандидатларга да җибәрә»;

4.4.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылучы кандидатларны тестлаштыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тестлаштыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Конкурс нәтиҗәләре турында 7 көнлек срокта хәбәр, аны тәмамлау көненнән соң кандидатларга язма рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга - дәүләт хезмәте өлкәсендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакытта Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла».;

4.14 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә бирелгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң системадан алынырга тиеш.»;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 22 ноябрендәге под - 2245/16 номерлы боерыгы белән расланган Положениегә 4 нче Кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета фоторәсемнәр белән;»;

«Башка дәүләт органында вазыйфа биләгән, конкурста катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре, министр исеменә һәм үзе кул куйган һәм ул граждан хезмәте вазыйфасын башкарган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гариза тапшыра, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча анкета, фотография белән.».

2. Кадрлар сәясәте бүлеге (Н.Б.Алексеева) боерык кабул ителгәннән соң,3 көнлек срокта, аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Бурганов